Татарстан Республикасы
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы

# Б О Е Р Ы К

2014 елның 9 декабрь Казан ш. № 233/2-пр

## Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “2014 – 2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү” федераль максатчан программасы турында” 2013 елның 12 октябрендәге 922 номерлы карарын үтәү максатында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының “2014 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында” 2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:.

1.1. Боерыкның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

“1.11. “2014 – 2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү” федераль максатчан программасы буенча мелиорация эшләрен башкарган өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә 2014 елда субсидияләр бирү тәртибен (51 нче кушымта);”;

1.2. Боерыкның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

“2.39. “2014 – 2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү” федераль максатчан программасы буенча агро-урман-мелиорация һәм фитомелиорация чараларына авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең чыгымнарының бер өлешен каплауга 2014 елда бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәсе формасы (52 нче кушымта);

2.40. “2014 – 2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү” федераль максатчан программасы буенча гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы мелиоратив системаларны һәм аерым урнашкан, авыл хуҗалыгы товарларын җигештерүчеләрнең милке булган яки аларга билгеләнгән тәртиптә файдалануга тапшырылган гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү, техник яңадан җиһазлау чыгымнарының бер өлешен каплауга 2014 елда бирелергә тиешле субсидияләр турында исәп-хисап белешмәсе формасы (53 нче кушымта).”.

2. Боерыкка 51, 52, 53 нче кушымталарны әлеге Боерыкка 1, 2, 3 нче кушымталарда бирелгән редакциядә бәян итәргә.

3. 6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасарлары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

2014 елның 09.12 233/2-пр номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
1 нче кушымта

2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр
номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
51 нче кушымта

“2014 – 2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү” федераль максатчан программасы буенча мелиорация эшләрен башкарган өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә 2014 елда субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип “2014 – 2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү” федераль максатчан программасы буенча мелиорация эшләрен башкарган очен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә, крестьян (фермер) хуҗалыкларына (алга таба – авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр) 2014 елда субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр бирүнең максатлары климатның үзгәрүчәнлеге һәм гадәти булмаган табигать шартларында авыл хуҗалыгы җитештерүчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм тотрыклылыгын, туфракның уңдырышлылыгын, мелиорацияләнә торган җирләрнең продуктив мөмкинлекләрен һәм табигать ресурсларыннан нәтиҗәле файдалануны арттырудан гыйбарәт.

3. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр аларның төп эшчәнлек юнәлешен үсемлекчелек продукциясен җитештерү тәшкил иткән очракта бирелә.

Бетерелә торган яки банкротлык турында эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр бирелми.

Субсидияләр гомуми яки индивидуаль файдаланудагы су белән тәэмин итү системаларын төзү, реконструкцияләү һәм техник яңадан җиһазлау буенча проект һәм тикшерү эшләрен башкаругаа һәм (яки) проект документациясен әзерләүгә тотыла алмый.

4. Авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә субсидияләр түбәндәгеләр очен бирелә:

а) гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы мелиоратив системаларны һәм аерым урнашкан, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең милке булган яки аларга билгеләнгән тәртиптә файдалануга тапшырылган гидротехник корылмаларны (алга таба – объектлар) төзү, реконструкцияләү, техник яңадан җиһазлау чыгымнарының бер өлешен каплауга. Гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы мелиоратив системаларны һәм аерым урнашкан гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү, техник яңадан җиһазлау чыгымнарыныц бер өлешен Татарстан Республикасы хуҗалыклары һәм муниципаль районнары

киселешендә каплаганда субсидиеләрнең күләме Программага кертелгән объектларныц төзелә башлавыннан алып башкарылган эшләр күләменец 50 процентыннан артык булмаган күләмендә исәпләп билгеләнә;

б) әзерлек, утырту, тәрбияләү эшләрен (ябалдашлары бер-берсенә тия башлаганчы) үз эченә алган агро-урман-мелиорация чараларына чыгымнарның бер өлешен каплауга.

5. Әлеге Тәртипнец 4 пунктындагы “а” пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан түбәндәге документлар тапшырыла:

субсидияләр бирү турында гариза, түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп;

объектларны төзү, реконструкцияләү, торгызу буенча җыелма смета исәп-хисапларының авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан таныкланган күчермәләре;

эшләр башкаруга подряд шартнамәләре;

эшләрне кабул итеп алу турында КС-2 статистика формасы буенча акт;

объект төзелә башлаганнан алып башкарылган эшләрнең һәм чыгымнарның бәясе турында КС-3 статистика формасы буенча белешмә;

Министрлыкның әлеге боерыгына 2 нче кушымта нигезендә субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәләре.

6. Әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы “б” пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен Министрлыкка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан түбәндәге документлар тапшырыла:

субсидияләр бирү турында гариза, түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп;

агро-урман-мелиорация чараларын башкаруга, ситуацион планны да кертеп, проект-смета документациясе;

Министрлыкның әлеге боерыгына 3 нче кушымта нигезендә субсидияләр бирү өчен исәп-хисап белешмәсе;

агро-урман-мелиорация чаралар буенча башкарылган эшләрнең кабул итеп алынуы турында КС-2, КС-3 статистика формалары буенча актларның күчермәләре.

Агро-урман-мелиорация чараларын башкару чыгымнарының бер өлешен каплауга документлар тапшырганда панорамалы фоторәсемнәрнең булуы мәҗбүри.

Эшләрнең башкарылуын раслый торган фотофиксация материалларына карата таләпләр:

фотографияләрнең зурлыгы: 10 х 15 см алып А4 форматына кадәр;

фоторәсемнәр төсле булырга тиеш;

фоторәсемнәрдә билгеле бер эш төрен башкару процессы һәм ахыргы нәтиҗә тасвирланган булырга тиеш;

фоторәсемнең арткы ягында предприятиенең, районның исеме, башкарыла торган эш төре һәм аны башкару көне күрсәтелгән булырга тиеш;

фоторәсемнәр предприятиенең җитәкчесе имзасы һәм предприятие мөһере беләп таныклана, көне күрсәтелә;

фоторәсемнәрдәге сурәтләр ачык булырга тиеш.

7. Әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы “а” пунктчасында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен өстәмә шарт - сугарыла торган кишәрлекне яки гидротехник корылманы мелиорация җиһазларының тәкъдим ителгән техник характеристикаларыннан чыгып һәм сугару системасының аерым өлешләрен урнаштыру схемалары буенча төзү яки торгызу мөмкин булу турында техник күзәтчелекне гамәлгә ашыра торган орган бәяләмәсе булу.

“Татарстан Республикасы буенча җирләр мелиорациясе һәм авыл хуҗалыгын су белән тәэмин итү идарәсе” федераль дәүләт бюджет учреждениесе техник күзәтчелекне (төзелеш контролен) гамәлгә ашыра торган орган булып тора.

Заказчы һәм техник күзәтчелек (тозелеш контроле) хезмәтен тотуга чыгымнарны финанслау программаны бюджет финанславы суммасыннан 2,14 процент күләмендә федераль бюджеттан башкарыла.

8. Министрлык бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм акчаларны 10 эш көне эчендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган үзенең хосусый счетыннан авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең исәп-хисап счетларына Министрлыкка авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан тапшырылган исәп-хисап белешмәләренә нигезләнеп күчерә.

9. Алынган субсидияләр аларны биргәндә әлеге Тәртиптә билгеләнгән шартның бозылуы, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу фактлары ачыклану буенча Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән алтмыш көн эчендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

10. Субсидияләр бирү турында килешүләрдә (шартнамәләрдә) каралган очракларда финанс хисабы елында тотылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр федераль бюджет керемепә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

11. Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджет керемепә үз ирекe белән кире кайтарудан баш тартылган очракта, алар законнар нигезендә мәҗбүри рәвештә түләттерелергә тиеш.

12. Министрлык субсидияләр бирү бирү шартлары, максатлары һәм тәртибенең авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләр тарафыннан үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшереп тора.

13. Тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә һәм Министрлыкның муниципаль районнардагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре башлыклары җаваплы була. Хокук бозучыларга карата законнарда каралган җаваплылык чаралары кулланыла.

14. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын тикшереп торуны Министрлык гамәлгә ашыра.

Раслыйм:
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының игенчелек буенча урынбасары:
____________________И.Х.Габдрахманов
«________»__________________, 2014 ел

09.12.2014 233/2-пр номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
2 нче кушымта

2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
52 нче кушымта

“2014 – 2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү” федераль максатчан программасы буенча агро-урман-мелиорация һәм фитомелиорация чараларына авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең чыгымнарының бер өлешен каплауга
2014 елда бирелергә тиешле субсидияләр турында
исәп-хисап белешмәсе

________________________________________________________________
(субсидияләр алучының исеме)

| т/б № | Объектның атамасы | Төзелеш башыннан алып объект буенча тотылган чыгымнар суммасы (сум) | Тотылган чыгымнарның 50 % ы күләмендә түләнергә тиешле сумма (сум) |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |

Тапшырылган документларның дөреслеген раслыйм:

Субсидияләр алучы оешманың җитәкчесе
__________________ __________________
(Имза) (Ф.И.А.и.)

ТР ____________________муниципаль районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы
__________________ __________________
(Имза) (Ф.И.А.и.)

Субсидияләр алучы оешманың баш бухгалтеры
__________________ __________________
(Имза) (Ф.И.А.и.)
Мөһер

Финанс – икътисад бүлеге башлыгы
__________________ __________________
(Имза) (Ф.И.А.и.)
Мөһер

Килештерелде:
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының сәясәт һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы__________________И.Ш.Гафуров

Раслыйм:
Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының игенчелек буенча урынбасары:
____________________И.Х.Габдрахманов
«________»_________________, 2014 ел

09.12.2014 233/2-п номерлы
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
3 нче кушымта

2014 елның 24 февралендәге 33/2-пр номерлы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына
53 нче кушымта

“2014 – 2020 елларга Россиянең авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләре мелиорациясен үстерү” федераль максатчан программасы буенча гомуми һәм индивидуаль файдаланудагы мелиоратив системаларны һәм аерым урнашкан, авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрнең милке булган яки аларга билгеләнгән тәртиптә файдалануга тапшырылган гидротехник корылмаларны төзү, реконструкцияләү, техник яңадан җиһазлау чыгымнарының бер өлешен каплауга 2014 елда бирелергә тиешле субсидияләр турында
исәп-хисап белешмәсе

_______________________________________________
(субсидияләр алучының исеме)

| т/б № | Объектның атамасы | Төзелеш башыннан алып объект буенча тотылган чыгымнар суммасы (сум) | Тотылган чыгымнарның 50 % ы күләмендә түләнергә тиешле сумма (сум) |
|---|---|---|---|
| 1. | | | |

Тапшырылган документларның дөреслеген раслыйм:

Субсидияләр алучы оешманың җитәкчесе
_________________ _________________
(Имза) (Ф.И.А.и.)

Субсидияләр алучы оешманың баш бухгалтеры
_________________ _________________
(Имза) (Ф.И.А.и.)
Мөһер

ТР ____________________муниципаль районында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы
_________________ _________________
(Имза) (Ф.И.А.и.)

Финанс – икътисад бүлеге башлыгы
_________________ _________________
(Имза) (Ф.И.А.и.)
Мөһер

Килештерелде:
ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының сәясәт һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы_________________И.Ш.Гафуров